РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Чемодуровского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Нагорная, д. 1А, Азнакаевский район,
с.Чемодурово, 423307,
тел./факс (885592)33-1-61
E-mail: Chmd.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирлеге
башкарма комитеты

Нагорная ур., 1 А йорт, Азнакай районы,
Чемодурово авылы, 423307
тел./факс (885592)33-1-61
E-mail: Chmd.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «14» октябрь 2022г.** **№ 24**

2021 елның 14 декабрь 30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1601 статьясындагы 32 пунктының өченче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл жирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елның 14 декабрь 30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе» 292 бүлекне түбәндәге эчтәлекле юллар белән тулыландырырыга:

| | | |
|---|---|---|
| «292 | 2 02 25576 10 0000 150 | Авыл территорияләрен комплексы үстерүне тәэмин итүгә авыл жирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 292 | 2 02 29999 10 0000 150 | Авыл жирлекләре бюджетларына башка субсидияләр |
| 292 | 208 10000 10 0000 150 | Түләүләр башкару өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл жирлекләре бюджетларына) акча күчерү |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Азнакай муниципаль районы сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Н.Б.Котельникова